**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
**IV чакырылыш**
423740, Актаныш авылы, Ленин пр., 17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-38.

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**IV созыва**
423740, село Актаныш, пр. Ленина, дом 17. Тел/. 3-44-44, факс 3-44-38.

КАРАР ПОСТАНОВЛЕНИЕ

Актаныш муниципаль районы Башлыгының кайбер карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе нигезләмәсен раслау турында» 2018 елның 17 июлендәге 29-03 номерлы карары нигезендә, Актаныш муниципаль районында Татарстан Республикасының коррупциягә каршы стратегиясен гамәлгә ашыру һәм кадрлар үзгәрешенә бәйле рәвештә,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Актаныш муниципаль районы Башлыгының «Актаныш муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү комиссиясе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2010 елның 06 декабрендәге ПГ-53 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

2. Актаныш муниципаль районы Башлыгының 2018 елның 22 июнендәге ПГ-24 номерлы карары «Актаныш муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия составына үзгәрешләр кертү турында»гы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар аңа кул куйган көннән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo/tatarstan.ru һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://aktanysh.tatarstan.ru.рәсми басылып чыгарга тиеш.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Муниципаль район Башлыгы Э.Н.Фәттахов